| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ УРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«29» ноябрь 2021 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш.

2.Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1.Тулбай торак пунктында Төньяк урамы буенча 46 һәм 58 нче йортлар арасында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2. Тулбай торак пунктында бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү (бүләкләр алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Тулбай торак пунктында юлларны кардан грейдлау, чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4. Җәйге чорда юл кырыйларын чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5. Тулбай торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекләрне буртлау, чүп чыгару, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6. Тулбай торак пунктында Социалистик урамы буенча сууткәргеч вентилен сатып алу һәм монтажлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3.Җыен нәтиҗәләрен Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://menzelinsk.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Урыс авыл җирлеге башлыгы: _______________ Аксюкова И.С.
(имза) (имзаны киңәйтү)